2023 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Сәрән авылы җирлеге Чуаш Сәрәне авылында гражданнарның үзара салымын кертү турында

ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

16 ноябрь 2022 ел № 6

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Сәрән авыл җирлегенең Чуаш Сәрәне авылында гражданнар җыены карар кабул итте:

1. 2023 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Сәрән авыл җирлегенең Чуаш Сәрәне авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче һәр балигъ булган кешедән 400 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә: су белән тәэмин итү системасын норматив хәлгә китерү, смета төзү өчен түләү, техник күзәтү үткәрү һәм җирлек милкенә рәсмиләштерү.

3. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Чуаш Сәрәне авылы, Үзәк урам, 34б йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Сәрән авыл җирлеге башлыгы Д.А.Севастьянов